**Кеше һәм гражданинның Конституция нигезендә билгеләнгән бурычлары**

РФ Конституциясе, кеше һәм гражданин хокуклары белән беррәттән, *конституция нигезендә билгеләнгән бурычларны да ныгыта*:

1) *РФ Конституциясен һәм законнарны үтәргә* (15 ст., 2 өлеш);

2) *башкаларның хокукларын һәм ирекләрен хөрмәт итәргә* (17 ст., 3 өлеш);

3) *ата-аналар балалар, аларны тәрбияләү турында һәм балигъ булган эшкә сәләтле балалар үзләренең эшкә сәләтсез ата-аналары турында кайтыртырга бурычлы* (РФ Конституциясе, 38 ст., 2, 3 өлешләр, РФ Гаилә кодексы);

4) *һәр кеше төп гомуми белемне алырга тиеш* һәм ата-аналар яки аларны алыштыручы затлар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) балаларның әлеге дәрәҗәдәге белемне алуларын тәэмин итәргә тиешләр (РФ Конституциясе, 43 ст. 4 өлеш);

5) *тарихи һәм мәдәни мирасны саклау турында кайгыртырга, тарихи һәм мәдәни яркарьләрне сакларга* (РФ Конституциясе , 44 ст., 3 өлеш);

6) *законда билгеләнгән салымнарны һәм җыемнарны түләргә* (РФ Конституциясе, 57 ст., РФ Салым кодексы);

7) *табигатьне һәм әйләнә-тирә мохитне сакларга, табигый байлыкларга сак карарга* (РФ Конституциясе, 58 ст.);

8) *Россия Федерациясе гражданнары Ватанны сакларга бурычлы* (РФ Конституциясе, 59 ст. 1 өлеш).